**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________ ______

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә агынты суларны агызуны (чыгаруны) гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын раслау**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 644 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агынты сулар составын һәм үзлекләрен тикшереп тору кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы карары нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә пычратучы матдәләрнең тискәре йогынтысын булдырмау максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә агынты суларны чыгаруны гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агынты сулар составының нормативларын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә агынты суларны чыгару белән шөгыльләнүче барлык абонентларга агынты сулар составының нормативларын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының https://aktanysh.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Р.А.Ильясов**

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
__________ №____ кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә агынты суларны чыгару белән шөгыльләнүче абонентлар өчен агынты сулар составы нормативлары**

| № | Пычраткыч матдәләр исемлеге | Агынты суларның составы нормативлары мг/дм3 |
|---|---|---|
| 1. | Алюминий | 5 |
| 2. | Алюминий-ион | 225 |
| 3. | АСПАВ | 15 |
| 4. | БПК5 | 300(500 < 3> ) |
| 5. | Үлчәнгән матдәләр | 300 |
| 6. | Тимер | 5 |
| 7. | Кадмий | 0.015 |
| 8. | Марганец | 1 |
| 9. | Бакыр | 1 |
| 10. | Нефть продуктлары | 10 |
| 11. | Никель | 0.25(0.5 < 6 >) |
| 12. | Нитратлар | 40 |
| 13. | Нитратлар | 0.8 |
| 14. | Свинец | 0.25 |
| 15. | Сульфат-анион | 1000 < 5> |
| 16. | Сульфид-анион | 1.5 |
| 17. | Коры калдык | 1650 |
| 18. | Фенол | 5 |
| 19. | Фосфат-ион (ТР буенча) | 34 |
| 20. | Кислородны химик куллану, ХПК | 500 (700 < 3> ) |
| 21. | Хлорид-анион | 1000 < 5 > |
| 22. | Цинк | 1 |
| 23. | Гомуми хром | 0.5 |
| 24. | Хром 6+ | 0.05 |

**Искәрмә:**

1. Майлар һәм нефть продуктлары канализация системасына бары тик эрегән һәм эмальгир халәттә генә чыгаруга рөхсәт ителә.

2. Исемлектә күрсәтелмәгән пычраткыч матдәләрне чыгару хуҗалык-эчү һәм балык хуҗалыгы файдалануындагы сулыкларда (ПДК минималь кыйммәте буенча) тиешле чик-рөхсәт ителгән концентрацияләрдән (ПДК)артмаган концентрацияләрдә рөхсәт ителә.